ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 27 ноябрь 2021 ел

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Түбән Якый авылында юлларны кардан чистарту;
- җәйге чорда Түбән Якый авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Түбән Якый авылында "Авыл бәйрәме" , «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү көне» бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәмнәр үткәрү, милли костюмнар сатып алу);
- "Сабантуй" бәйрәме үткәрү территориясен төзекләндерүне оештыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);
- Түбән Якый авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);
- халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен

түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау;

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин